**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Ташлы-Ковали, ул. Школьная, 94

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы Кавал ав., Мэктэп ур., 94

Тел./факс 8(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18 июль 2022 ел** **№ 43**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 171 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 10.08.2020 № 186, 19.01.2021 N16 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 октябрьдэ 31 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы Кавал авылы, Школьная урамы, 94 нче йорт адресы буенча 2021 елның 25 октябрендә 10 сәгатьтә үткәрелгән ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында «карар проекты хакында»2021 елның 5 октябрендәге 31 номерлы карары нигезендә гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 171 номерлы карары белән кабул

ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 10.08.2020 № 186, 19.01.2021 N16 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы И.И.Хайбуллин